**СОВЕТ КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422626 с. Кирби,
ул. Горького, д.26а
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422626 Хәерби авылы,
Горкий урамы, 26а нчы йорт,
тел: 4-38-16

**2024 елның 11 ноябре** **153 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры вазыйфаи оклады күләмен арттыру турында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш)**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш), Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 25 апрелендәге 138 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның хезмәт хакы түбәндәге зурлыкта билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны белән муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр |
| Баш бухгалтер | 25 700 рублей |

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге башкарма комитетының штат расписаниесенә баш бухгалтер вазифасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 мең кешедән артык.».

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Хәерби**
**авыл җирлеге Советы рәисе Р.К.Зинәтуллин**